**Каралды**
**Башлангыч сыйныф**
**укытучыларының**
**мәктәп методик берләшмә**
**җитәкчесе_________Тухбатуллина Э.М.**
**Беркетмә № 1**
**« 26 » август 2017 ел.**

**Килешенгән**
**Укыту эшләре буенча**
**директор урынбасары**
**_________Исмәгыйлева Г.Т.**
**“ 28 ” август 2017ел**

**Раслыйм**
**Мәктәп директоры**
**_____ Сабирҗанова Г.Т.**
**Приказ №**
**« 28 » август 2017 ел**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**“ Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе”**
**муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

# Татар теленнән
# эш программасы

**3 нче сыйныф**

**Хаҗиева Люзия Нәҗип кызы, югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**

Каралды
Мәктәп педагогик советы
утырышы беркетмәсе № 1
28 нче август, 2017 ел

**2017 – 2018 нче уку елы**

**Татар теленнән 3 нче сыйныф өчен эш программасына аннотация**

Эш программасы “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль); “2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (2004 ел, 11 октябрь); Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь); Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. - ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре, Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә;МБГББУ «Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» белем бирү программасы, “Укыту курсы һәм предметының эш программаларынраслау һәм эшләү тәртибе структурасы” турындагы нигезләмәсенә, мәктәпнең 2017-2018 нче уку елына базис укыту планына нигезләнеп эшләнде.

Татар теле филология өлкәсенә карый. Татар теле фәне 3 нче сыйныфта атнага 4 сәгать исәбеннән 136 сәгать укытыла.

## Аңлатма язуы

Эш программасы "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль); "2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы" (2004 ел, 11 октябрь); Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь); Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. - ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре, Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2010; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә;МБГББУ «Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» белем бирү программасы, "Укыту курсы һәм предметының эш программаларын раслау һәм эшләү тәртибе структурасы" турындагы нигезләмәсенә, мәктәпнең 2017-2018 нче уку елына базис укыту планына нигезләнеп эшләнде.

**Программа елга 136 сәгать (атнага 4 сәгать) каралган.**

Программа үтәлү өчен түбәндәге **укыту-методик әсбаплар** кулланыла:

- И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова. Татар теле 3 нче сыйныф: Дәреслек. Ике кисәктән тора - Казан: «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2013;
- И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова. Татар теле. 3 нче сыйныф: Методик кулланма.- Казан «Мәгариф-вакыт"нәшрияты, 2013.

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш"**. Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.

«Перспектив башлангыч мәктәп»нең 3 нче сыйныфы өчен төзелгән татар теле программасы укытуның максатын, бурычларын һәм эчтәлеген билгели. Тәкъдим ителә торган программада татар теленә өйрәтүнең **төп максаты һәм бурычлары** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

-балаларның сөйләм осталыгын, фикерләү сәләтен һәм иҗади хыялын үстерү, ана телендә аралашу максатына, бурычларына,шартларына туры килгән тел чаралары сайлый белергә, уй-фикерләрен төгәл белдерергә һәм әңгәмәдәше әйткәнне тәңгәл аңларга күнектерү

-телнең лексикасы,фонетикасы һәм грамматикасы буенча программада күрсәтелгән башлангыч белемнәрне үзләштерүгә ирешү

-укучыларда дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, диалогта катнашырга һәм аларны зур, катлаулы булмаган монолог тибында төзеп әйтергә, тасвирлама, хикәяләү, фикер йөртү төрендәге кечкенә текстлар төзергә өйрәтү, уңышлы аралашу сәләте тәрбияләү

**Татар теле дәресенең максаты:**

-укучыларда уңышлы аралашу сәләте булдыру-әйтмә һәм язма сөйләмне үстерү, кара-каршы сөйләшү осталыгы, монолог төзү һәм шулай ук гомуми культура күрсәткече булган грамоталы язу күнекмәләре булдыру, укучыларны тел фәненең төп мәгълуматлары белән таныштыру һәм шулар нигезендә аларның тамга символик һәм логик фикерләвен үстерү, татар теленең башка телләр белән берлектә дөньяның фәнни картинасын тудыруда катнашуы,аның милләте саклап калуда, халыкның, шәхеснең үзенчәлеген югалтмауда ышанычлы нигез, җәмгыятнең яшәешенә зарури шарт булуы турында күзаллау барлыкка китерү.

### Предметның укыту планындагы урыны

Татар теле филология өлкәсенә карый. Татар теле фәне 3 нче сыйныфта атнага 4 сәгать исәбеннән 136 сәгать укытыла.

**Искәрмә:** «Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль гомуми белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында»гы 2016 нчы елның 29 нчы августында педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килгән очракта, программа сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

**Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре**

**Бирелгән программа буенча укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

**Укучылар белергә тиеш :**

- кушма сүз, парлы сүз; тамыр һәм ясалма сүзләр;
- өйрәнелгән сүз төркемнәрен һәм аларның билгеләрен : исем, фигыль, сыйфат, зат алмашлыклары, алмашлык, кисәкчә, бәйлек;

**Укучылар башкара алырга тиеш :**

- сүзләрдәге орфограммаларны табу һәм аларның язылышын кагыйдәләргә нигезләнеп аңлату;
- үтелгән орфограммалар кергән 55-60 сүзле текстны хатасыз һәм каллиграфик итеп күчереп һәм ишетеп, тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;
- сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерү;
- сүзнең тамырын һәм кушымчаларын табу;
- кушымчаларның төрен билгеләү;
- кушма һәм парлы сүзләрне билгеләү;
- сүзләрне сүз төркеме ягыннан тикшерү : исемнең сан, килеш кушымчасын билгеләү;
- сыйфатның дәрәҗәләрен аеру;
- фигыльнең зат – сан, заманын күрсәтү;
- текстның темасын, төп фикерен билгеләү;
- темага һәм төп фикергә таянып, текстка исем кую;
- текстның планын төзү;
- хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү һәм сөйләмдә куллану;
- культуралы мөгамәлә таләпләренә туры китереп, үтенеч, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, баш тарту, чакыру, котлау – тәбрикләү сүзләрен сөйләмдә куллану;
- тасвирлау һәм фикер һөртү элементлары кергән 70-75 сүзле хикәяне изложение итеп язу;
- хикәяләү характерындагы сочинение язу.
- кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.
- программада булган сүзләрне дөрес язу һәм юлдан –юлга күчерү
- сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу,
- үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру

- сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны ,предметның эшен,хәрәкәтен, билгесен, өстәмә предметны, ярдәмче сүзләрне таба белү

- җөмләнең баш кисәкләрен таба белү; уку, уеннар, көндәлек тормыш, табигать турындагы темаларга 7-8 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу

- сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: *авыр,акбур,акош,алъяпкыч, ап-ак, аръяк, ашъяулык, аю,әдип,әти-әни, әһәмият, бала-чага, әһәмият, берәз, бияләй, булдыклы, буяу, вак, Ватан,гади, гаилә,гайртле, давыл, данә, дөя, егрле, елан, җәелә, җәза, җәнлек, җиз, җиһаз, илле, йокы, кадерле, карабүрек, кәгазь, кәккүк, кием, кошчык, котлы, көе, көнбагыш, көньяк,көянтә, куәтле, күбрәк, күңелле, мәгънә, мәкаль, мәсьәлә, мәңге, милләт, морҗа, нәүрәз, ният, охшый, ошый, өрәңге,өянке, пөхтә, рөхсәт, русча, сава, салават, саңгырау, сәгать, сәламәт, сәхнә, сәяхәт, соңгы, сөенеч, сөяк, табигать,ташбака, таң, тәңкә, тиеш, тимераяк, тозсыз, төяк, төен, төнбоек, төньк, тыңлау, уйсу, үрмәкүч, чаңгы, чәучәк, чәүкә, чуар, чынаяк, шигырь, элекке, эре, юаныч, юаш, юкә, юлчы, юнәлеш, юына, ябалак, явыз, якты, ямьле, япь, ярдәм, ятьмә,яхшы, яшь.*

**Шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләр**

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- туган илгә карата шәхси караш булдыру;
- чын кеше сыйфатлары булдыру;
- мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү;
- этик хисләр, мөлаемлылык үстерү;
- рухи-әхлакый идеалларына китерү.
- олылар белән хезмәттәшлек;
- аралашу культурасы күнекмәләре .

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

- аң -белем үстерү;
- проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу;
- эзләнү юлларын һөм нәтиҗәләрен ачыклау;
- логик фикерләү:чагыштыру, синтез, анализ ясый белү;
- конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу;
- укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү;

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- Россиядә күп милләт халыкларының төшенчәсен бирү;
- татар теленең төп төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик);
- татарча югары сөйләм культурасы формалаштыру;
- туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре;
- сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру;
- уку, язу гамәлләре формалаштыру;
- сүзгә фонетик анализ ясый белү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

***Танып белү универсаль уку гамәлләре:***

- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

***Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:***

- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***

- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү;
- үз фикереңне һәм позицияңне формалаштыру;
- уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килү;
- партнёрның нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә, сораулар бирү;
- партнёрның эш-гамәлләрен контрольгә алу;
- сөйләмнең диалог формасын үзләштерү.

## Укыту предметының эчтәлеге

| № | Эчтәлек | Сәг. саны |
|---|---|---|
| 1 | Орфограмма.1-2 сыйныфта үткәннәрне кабатлау. | 13 сәг. |
| 2 | Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.- | 11 сәг. |
| 3 | Сүз төзелеше.Сүз ясалышы. | 11 сәг. |
| 4 | Сүз төркемнәре | |
| | Исем | 17 сәг. |
| | Фигыль | 24 сәг. |
| | Сыйфат | 9 сәг. |
| | Алмашлык | 5 сәг. |
| | Кисәкчәләр | 4 сәг. |
| | Бәйлекләр | 2 сәг. |
| 5 | Җөмлә | 13 сәг. |
| 6 | Сүзтезмә. | 3 сәг. |
| 7 | Текст.Бәйләнешле сөйләм | 10 сәг. |
| 8 | Ел буена үткәннәрне кабатлау | 14 сәг. |
| | Барысы | 136 сәг. |

**Программа эчтәлеге (136 сәг.)**

**Орфограмма. 1-2 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау (13 сәг.)**
Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тавышсыз хәрефләр. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар.Калын һәм нечкә сузык авазлар. Е,я,ю хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу. Ъ, ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку. Сүзгә фонетик анализ ясау.

**Сүз. Телнең сүзлек байлыгы (11 сәг.)**
Сүз.Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар. Аларның сөйләмдәге роле. Сүзнең күп мәгънәлелеген һәм күчерелмә мәгънәсен (фразеологик әйтелмәләр) куллану. Татар теленең сүз байлыгы. Дәреслекләрдәге сүзлекчәләрдән, сүзлекләрдән сүзнең аңлатмасын табып алу.
Сүзтезмә белән белдерелгән лексик берәмлекләр: сөт өсте, җир җиләге һ.б.

**Сүз төзелеше. Сүз ясалышы (11 сәг.)**
Морфология һәм аның состав өлешләре. Бер тамырдан берничә сүз ясалу, кушымчалар, аларның яңа сүз ясаудагы роле.
Тамырдаш сүзләр. Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре (ясалма, кушма, парлы сүзләр).

**Сүз төркемнәре**

**Исем (17 сәг.)**
Сүз төркемнәре төшенчәсе. Исем. Исемнең предметлык төшенчәсен белдерүе, аның җөмләдә ия булып килүе. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрне тематик төркемләү.
Исемнең берлек һәм күплек санда килүе. Күплек кушымчалары, аларның дөрес әйтелеше һәм ясалышы.
Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Сузык авазларга һәм яңгырау тартыкларга беткән исемнәрнең килешләр белән төрләнүе.

**Фигыль (24 сәг.)**
Фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары. Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльөч заманы: үткән заман, киләчәк заман, хәзерге заман.Фигыльнең заман формаларын дөрес ясау. Фигыльнең күп мәгънәлелеге.

**Сыйфат (9 сәг.)**
Сыйфатларның семантик төркемнәре. Сыйфат дәрәҗәләре (гади, чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләре).

**Алмашлык (5 сәг.)**
Алмашлыкның мәгънә үзенчәлегенә –зат һәм предметны атамыйча, исемен генә алыштырып килүенә күзәтүләр. Зат алмашлыклары, килеш белән төрләнүе. Аларның җөмләләрне бер-берсенә бәйләүдәге роле.

**Кисәкчәләр (5 сәг.)**
*Да-дә, та-тә* кисәкчәләрен *-да/-дә, -та/-тә* кушымчаларыннан аеру. Кисәкчәләрне дөрес язу.

**Бәйлекләр (2 сәг.)**
Төрле килешләрдә исемнәрне һәм зат алмашлыкларын *белән, саен, шикелле, өчен, аркылы, таба, хәтле, каршы, кадәр, чаклы, бирле, соң, башка* бәйлекләре белән куллану.

**Җөмлә (12 сәг.)**
Хикәя, сорау, өндәү (боеру), тойгылы җөмләләр. Аларны текстта аера белү.
Җөмләнең әйтелү максаты буенча төрләренә карап, җөмлә ахырына тыныш билгесе кую. Җөмләнең баш кисәкләре . Язма сөйләмдә ия һәм хәбәрнең урыннары.
Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак җөмләне, тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару.
**Сүзтезмә (3 сәг.)**
Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү, мәгънәләре, сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләр бәйләнешен ачыклау, сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне билгеләү**.**
**Бәйләнешле сөйләм (10 сәг.)**
Текстның темасын һәм төп фикере. Исемсез текстларның темасын билгеләү һәм исем кую. Төп фикерне темадан аера белү һәм аларны төгәл билгеләү.
Текстның типлары: хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү. Аларның төп үзенчәлекләре.
Әзер яки күмәк төзелгән план буенча хикәяләү тибындагы текстны изложение итеп язу. Сюжетлы рәсемнәр һәм картиналар буенча укучыларның тормыш тәҗрибәсенә, күзәтүләренә, укыганнарына бәйле темаларга сочинениеләр язу. Телдән эш характерындагы текстлар төзү.
Сөйләм этикасы. Телдән һәм язмача чакыру, тәбрикләү.
**Ел буена үткәннәрне кабатлау (14сәг.)**
“Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе” темасы.Сүз төзелеше. Сүз ясалышы.Сүз төркеме.

## Уку материалын календарь - тематик планлаштыру

| № | Дәрес темасы | Үткәрү вакыты | | Укучы эшчәнлеге төре |
|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | |
| **Орфограмма. 1-2 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. (13сәг.)** | | | | |
| 1. | Орфограмма | 4.09 | | Сүзлекләр белән эшләү |
| 2. | Бәйләнешле сөйләм. Рәсем буенча хикәя язу “Җәй көне” | 5.09 | | Хикәя төзү. Сүзлекләр белән эшләү |
| 3. | Авазлар һәм хәрефләр | 6.09 | | Күнегүләр эшләү |
| 4 | Сузык һәм тартык авазлар | 7.09 | | Рәсемнәр буенча әңгәмә, күнегүләр, тиешле хәрефләрне куеп язу, җөмләләр төзү |
| 5 | Сузык һәм тартык авазлар | 11.09 | | Парларда эш, тартык авазлар, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру, парлау |
| 6. | Иҗек. Сүзләрне юлдан юлга күчерү | 12.09 | | Иҗек төзелеше, саны, аваз һәм иҗек анализы Сүзләрне юлдан юлга күчерү |
| 7. | Ъ, Ь хәрефләре | 13.09 | | Сүзләрне юлдан юлга күчерү, иҗеккә бүлү буенча биремнәр үтәү |
| 8. | Я, ю, е хәрефләре. Алфавит | 14.09 | | Я,ю,е хәрефләре кергән сүзләрне язу алфавит тәртибе; аваз һәм хәреф саны, әйтелеше, исеме, язылышы; сүзлекләр белән эшләү |
| 9. | **Кереш диктант**.№1 | 18.09 | | Орфограммаларны кулланып, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгесе куеп, диктант язу; |
| 10. | Хаталар өстендә эш. Тамыр һәм кушымча. Тамырдаш сүзләр | 19.09 | | Парларда эш,сүз төзелеше, тамыр һәм кушымчаны билгеләү; тамырдаш сүзләр табу |
| 11. | Сүз төркемнәре. Җөмлә. | 20.09 | | Күнегүләрне эшләү, сорауларга җавап бирү |
| 12. | “Орфограммалар” темасы буенча **тест** | 21.09 | | Сүзлекләр белән эшләү, аваз-хәреф анализы. Тест эшләү. |
| 13. | Хаталар өстендә эш.Үткәннәрне кабатлау | 25.09 | | Татар һәм рус телләрендә [о], [ы], [е/э] сузыклары. Татар сүзләрендә аларның – кыска авазлар, ә рус теле аша кергән сүзләрдә, аларның – озын авазлар дип йөртелүе. Сүзләрдәге иҗекләр санының авазларга бәйле булуы |
| **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы (11 сәг.)** | | | | |
| 14. | Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе | 26.09 | | Лексик төшенчәсен аңлату,аңлатмалы сүзлекләр белән эш,хезмәтләрне бәяләү, төзәтү; татар теленең сүз байлыгы, сүзнең лексик мәгънәсе; лексик мәгънәгә туры килгән сүзләр табу |
| 15. | Алынма сүзләр | 27.09 | | Парларда эш,сүз байлыгы; төрле телләрдән кергән сүзләр, кулланылу өлкәсе |
| 16. | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр | 28.09 | | Сүзләрнең мәгънәләре, туры һәм күчерелмә мәгънә; сөйләмдә куллану |
| 17. | Әйтелеше бертөрле, мәгънәләре башка сүзләр – омонимнар | 2.10 | | Сүзләрнең мәгънәләре, сорау кую; омоним төшенчәсе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Охшаш мәгънәле сүзләр – синонимнар. | 3.10 | | Иҗади эш, сүзләрнең мәгънәләре, синоним төшенчәсе. |
| 19 | Охшаш мәгънәле сүзләр – синонимнар.**Контроль күчереп язу.№1** | 4.10 | | Парларда эш,сүзләрнең мәгънәләре, синоним төшенчәсе; кулланылыш сферасы, контроль күчереп язу |
| 20 | Капма-каршы мәгънәле сүзләр – антонимнар | 5.10 | | Күнегүләр эшләү, тиешле хәрефләрне куеп язу |
| 21 | Капма-каршы мәгънәле сүзләр – антонимнар | 9.10 | | Хикәя төзү. Сүзлекләр белән эшләү. |
| 22. | Тотрыклы сүзтезмәләр | 10.10 | | Тотрыклы сүзтезмәләр яисә фразеологик әйтелмәләр белән танышу |
| 23. | “Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе” темасына искәртмәле **диктант** “Тоз”. | 11.10 | | Сүзлекләр белән эшләү. Диктант язу |
| 24. | Хаталар өстендә эш. Теманы кабатлау. | 12.10 | | Хаталар өстендә эш |
| **Сүз төзелеше. Сүз ясалышы (10 сәг.)** | | | | |
| 25 | Тамыр һәм кушымча | 16.10 | | Хезмәтләрне анализлау; тамыр һәм кушымчаны табу, билгеләү, нечкә һәм калын кушымчалар |
| 26. | Сүз ясагыч кушымчалар | 17.10 | | Сүз ясалышы, ясагыч кушымчалар, алар ярдәмендә сүзләр ясалуын карау, ясау; ясалма сүзләр |
| 27. | Төрләндергеч кушымчалар | 18.10 | | Төрләндергеч кушымчалар, алар ярдәмендә сүзләрнең үзгәрүен күзәтү; үзгәртү,парларда эш |
| 28. | **Изложение “Көзге урман”№1** | 19.10 | | Күнегүләр эшләү. башваткыч чишү, яңгырау тартыкларның астына сызу |
| 29 | Кушма сүзләр | 23.10 | | Ясалма сүзләр: кушма сүзләр, аларның ясалышы |
| 30. | Кушма сүзләр | 24.10 | | Таблица буенча эш, күнегүләр , сорауларга җавап бирү |
| 31 | **1 чирек нәтиҗәләре буенча контроль диктант№2**.”Матурлык”. | 25.10 | | Контроль диктант язу |
| 32 | Парлы сүзләр Хаталар өстендә эш | 26.10 | | Күнегүләр эшләү, тиешле хәрефләрне куеп язу, җөмләләр төзү |
| 33. | Парлы сүзләр | 6.11 | | |
| 34. | “Сүз төзелеше. Сүз ясалышы” темасын кабатлау. | 7.11 | | Хаталар өстендә эш. Төзелеше ягыннан сүзләр тикшерү |
| **Исем ( 17 сәг.)** | | | | |
| 35. | Сүз төркемнәре. Сүзләрнең төркемнәргә бүленеше | 8.11 | | Сүзлекләр белән эшләү. Җөмләдән исемнәрне табу. Сүзләрне төркемнәргә бүлү. |
| 36. | Исем. Мәгънәсе, сораулары, җөмләдәге роле | 9.11 | | Күнегүләр эшләү, тиешле хәрефләрне куеп язу, җөмләләр төзү |
| 37 | Ялгызлык исемнәр | 13.11 | | Исемнәрне табу, сорау кую. |
| 38 | Ялгызлык исемнәр | 14.11 | | |
| 39. | Уртаклык исемнәр | 15.11 | | Уртаклык төшенчәсе, язылышы, алган белемнәрне практикада куллану |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 40. | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр | 16.11 | | Берлек һәм күплек сан формалары, берлектән-күплек, күплектән-берлек ясау; борын авазларын тану. |
| 41. | “Берлек һәм күплек сандагы исемнәр” темасын кабатлау. Изложение “Песи баласы” | 20.11 | | Сүзлекләр белән эшләү. Күплек форма ясау, язылышы, изложение язу |
| 42. | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 21.11 | | Килеш төшенчәсе, җөмләдә бәйләүче роле, атамалары, сораулары; калын һәм нечкә төрләнеш |
| 43. | Баш килеш | 22.11 | | Исемнәрне табу, сорау кую, баш килеш төшенчәсе, сораулары |
| 44. | Иялек килеше | 23.11 | | Парларда эш, исемнәргә сорау кую; иялек килеш төшенчәсе, сораулары, кушымчары; калын һәм нечкә төрләнеш |
| 45. | Юнәлеш килеше | 27.11 | | Исемнәргә сорау кую; юнәлеш килеше төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; саңгырау һәм яңгырау тартыкларга, сузык авазга беткән исемгә кушымча ялгау |
| 46. | Төшем килеше | 28.11 | | Исемнәргә сорау кую; төшем килеше төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; саңгырау һәм яңгырау тартыкларга, сузык авазга беткән исемгә кушымча ялгау |
| 47. | Чыгыш килеше | 29.11 | | Исемнәргә сорау кую; чыгыш килеш төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; борын авазларына беткән исемнәргә чыгыш килеш кушымчасын ялгау |
| 48. | Урын-вакыт килеше | 30.11 | | Исемнәргә сорау кую; урын-вакыт килеше төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш |
| 49. | “Исемнәрнең килеш белән төрләнеше” темасын ныгыту | 4.12 | | Исемнәргә сорау кую; килешен билгеләү. |
| 50. | “Исемнәрнең килеш белән төрләнеше” темасы буенча иҗади **диктант** | 5.12 | | Диктант язу |
| 51. | Хаталар өстендә эш. “Исем” темасын кабатлау | 6.12 | | Хаталар өстендә эшләү Исемнәргә сорау кую; килешен билгеләү |
| **Фигыль ( 24 сәг.)** | | | | |
| 52. | Фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары | 7.12 | | Җөмләдән фигыльне табу. Фигыльләрнең мәгънәләрен ачыклау |
| 53 | Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре | 11.12 | | Фигыльләрнең мәгънәләрен ачыклау. Фигыльне юклык формага кую |
| 54 | Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре **Контроль күчереп язу№2** | 12.12 | | Контроль күчереп язу |
| 55. | Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше | 13.12 | | Сүзлекләр белән эшләү |
| 56. | “Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше” темасын ныгыту | 14.12 | | Фигыльне зат-сан белән төрләндерү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 57. | **1яртыеллык буенча контроль диктант№ 3**“Карлар ява”. | 18.12 | | Контроль диктант. |
| 58. | Хаталар өстендә эш. Фигыль заманнары. Хикәя фигыль | 19.12 | | Сүзлекләр белән эшләү. Хаталар өстендә эш. |
| 59. | Хикәя фигыльнең заман белән төрләнеше | 20.12 | | Фигыльне заман белән төрләндерү |
| 60. | Хәзерге заман хикәя фигыль | 21.12 | | Фигыльне заман белән төрләндерү. Билгеле һәм билгесез үткән заман, аның кушымчалары, язылышы |
| 61. | Үткән заман хикәя фигыль | 8.01 | | Сүзлекләр белән эшләү. Җөмләдән фигыльне табу. |
| 62 | Үткән заман хикәя фигыль | 9.01 | | Үткән заман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, сөйләмдә аларны аера белү |
| 63. | “Үткән заман хикәя фигыль” темасы буенча **контроль күчереп язу№3** | 10.01 | | Фигыльне төрле зәаманга кую. Контроль күчереп язу |
| 64. | Хаталар өстендә эш. Киләчәк заман хикәя фигыль | 11.01 | | Фигыльне заман белән төрләндерү |
| 65 | Киләчәк заман хикәя фигыльнең беренче төре | 15.01 | | Сүзлекләр белән эшләү |
| 66 | Киләчәк заман хикәя фигыльнең беренче төре | 16.01 | | Фигыльне заман белән төрләндерү |
| 67 | Киләчәк заман хикәя фигыльнең икенче төре | 17.01 | | Парларда эш, киләчәк заман хикәя фигыльнең икенче төре; калын һәм нечкә төрләнеш; тамырда авазлар чиратлашуы |
| 68 | Киләчәк заман хикәя фигыльнең икенче төре | 18.01 | | |
| 69. | “Киләчәк заман хикәя фигыль” темасын ныгыту | 22.01 | | |
| 70 | Фигыльләрнең күп мәгънәлелеге | 23.01 | | Боерык фигыльне табу. Фигыльләрнең мәгънәләрен ачыклау |
| 71 | Фигыльләрнең күп мәгънәлелеге | 24.01 | | Фигыльләрнең мәгънәләрен ачыклау. Синоним, антоним фигыльләр һәм сыйфатлар, сөйләмдә куллану |
| 72. | “Фигыльләрнең күп мәгънәлелеге” темасы буенча изложение ”Чыршы бәйрәме”. | 25.01 | | Сүзлекләр белән эшләү. Парларда эш, иҗади эш, фигыль төзелеше, анализлау |
| 73. | Хаталар өстендә эш. “Фигыльләрнең күп мәгънәлелеге” темасын ныгыту | 29.01 | | Хаталар өстендә эш |
| 74. | “Хикәя фигыль” темасы буенча **аңлатмалы диктант** | 30.01 | | Аңлатмалы диктант язу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 75. | Хаталар өстендә эш. “Фигыль” темасын кабатлау | 31.01 | | Фигыльне заман белән төрләндерү |
| **Сыйфат (10сәг.)** | | | | |
| 76 | Сыйфатлар нәрсәне белдерәләр | 1.02 | | Сүзлекләр белән эшләү |
| 77 | Сыйфатлар нәрсәне белдерәләр | 5.02 | | Сыйфатны җөмләдә куллану |
| 78. | Сыйфат дәрәҗәләре. Гади дәрәҗәдәге сыйфатлар | 6.02 | | Сыйфат дәрәҗәләре төп (гади) , чагыштыру, артыклык, кимлек, сыйфат дәрәҗәләренең ясалышы, аларның дөрес язылышы |
| 79. | “Гади дәрәҗәдәге сыйфатлар” темасы буенча **ирекле диктант.** “Әниемә бүләк”. | 7.02 | | Ирекле диктант язу |
| 80. | Хаталар өстендә эш. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар | 8.02 | | Хаталар өстендә эш. |
| 81. | Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар | 12.02 | | Сыйфат дәрәҗәләре төп (гади) , чагыштыру, артыклыккимлек, сыйфат дәрәҗәләренең ясалышы, аларның дөрес язылышы |
| 82. | Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатлар | 13.02 | | |
| 83. | “Сыйфат дәрәҗәләре” темасын ныгыту | 14.02 | | |
| 84. | “Сыйфат дәрәҗәләре” темасы буенча искәртмәле **диктант**. “Мияубикә” | 15.02 | | Орфограммаларны кулланып диктант язу, |
| 85. | Хаталар өстендә эш. “Сыйфат” темасын кабатлау | 19.02 | | Сүз төркемнәрен билгеләү |
| **Алмашлык ( 5 сәг.)** | | | | |
| 86. | Алмашлык | | | Алмашлыклар белән җөмлә төзү |
| 87 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнәнеше | 20.02 | | Сүзлекләр белән эшләү |
| 88 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнәнеше | 21.02 | | Берлек сандагы зат алмашлыкларын килеш белән төрләндерү; дөрес әйтелеш һәм язылыш |
| 89. | “Алмашлык” темасы буенча **контроль күчереп язу№4. “**Мәңге сүнмәс умырзаялар”. | 22.02 | | Контроль күчереп язу |
| 90. | Хаталар өстендә эш. “Алмашлык” темасын ныгыту | 26.02 | | Алмашлыклар белән җөмлә төзү. |
| **Кисәкчәләр ( 4 сәг.)** | | | | |
| 91 | Кисәкчәләр | 27.02 | | Кисәкчәләр кулланып җөмлә төзү |
| 92 | Кисәкчәләр | 28.02 | | Кисәкчәләр кулланып җөмлә төзү |
| 93. | “Кисәкчәләр” темасын ныгыту | 1.03 | | Кисәкчәләр кулланып җөмлә төзү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 94. | Рәсем буенча хикәя язу | 5.03 | | Рәсем буенча хикәя язу |
| 95. | Бәйлекләр | 6.03 | | Хезмәтләрне анализлау, ярдәмче сүз төркеме буларак бәйлек; җөмләдәге роле Сүзлекләр белән эшләү |
| 96. | “Бәйлекләр” темасы буенча изложение | 7.03 | | Изложение язу. Бәйлекнең җөмләдәге роле. Бәйлекләр кулланып җөмлә төзү |
| **Җөмлә (13 сәг.)** | | | | |
| 97 | Нәрсә ул җөмлә? | 8.03 | | Сүзлекләр белән эшләү. Әйтелү максаты ягыннан төрле җөмләләр төзү |
| 98. | Хикәя җөмлә | 12.03 | | Әйтелү максаты ягыннан төрле җөмләләр төзү |
| 99. | Сорау җөмлә | 13.03 | | Әйтелү максаты ягыннан төрле җөмләләр төзү |
| 100 | Сорау җөмлә | 14.03 | | Әйтелү максаты ягыннан төрле җөмләләр төзү |
| 101 | Өндәү (боеру) җөмлә. Тойгылы җөмлә | 15.03 | | Парларда эш, әйтелеш максаты буенча төрләре- өндәү җөмлә, белдерелеше, тыныш билгесе, җөмләләр төзү. Көчле төйгы белән җөмлә төзү |
| 102 | Өндәү (боеру) җөмлә. Тойгылы җөмлә**з** | 19.03 | | |
| 103 | **3 чирек нәтиҗәләре буенча контроль диктант№4** | 20.03 | | Диктант язу |
| 104 | Хаталар өстендә эш. Җөмлә кисәкләре | 21.03 | | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре: ия һәм хәбәр, аларның белдерелеше, сораулары, язуда билгеләү |
| 105 | Җөмлә кисәкләре | 22.03 | | Җөмлә кисәкләрен билгеләү тәртибе, аларның аталышы, сораулар кую |
| 106 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр | 4.04 | | Җыйнак, җәенке җөмләләр төзү |
| 107 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр | 5.04 | | Тиңдәш кисәкләр кулланып җөмлә төзү |
| 108 | “Җөмлә” темасы буенча ирекле д**иктант** | 9.04 | | Диктант язу, җөмлә кисәкләрен билгеләү |
| 109. | Хаталар өстендә эш. “Җөмлә” темасы буенча үткәннәрне ныгыту | 10.04 | | Хезмәтләргә бергәләп бәя бирү, хаталарны төзәтү; җыйнак һәм җәенке җөмлә төшенчәсен аңлату; чагыштыру, аеру, куллану |
| **Сүзтезмә ( 3 сәг.)** | | | | |
| 110. | Сүзтезмә | 11.04 | | Сүзтезмә төшенчәсе, аларны аера белү, сораулар кую |
| 111 | Сүзтезмә | 12.04 | | Җөмләдә сүзләр бәйләнешен билгеләү. Сүзлекләр белән эшләү |
| 112 | Сүзтезмә | 16.04 | | Җөмлә кисәкләрен билгеләү |
| **Бәйләнешле сөйләм (11сәг.)** | | | | |
| 113 | Текст. Бәйләнешле сөйләм | 17.04 | | Әйтмә һәм язма сөйләм; текст, текстның өлешләре, мәгънәле кисәкләре арасында бәйләнеш; исем кую, хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү төрләрен аеру текстның төп уе- тема; теманы билгеләү, мисаллар китерү мәгънәле кисәкләрне билгеләп гади план төзү. |
| 114 | Текст. Бәйләнешле сөйләм | 18.04 | | |
| 115 | Текст. Бәйләнешле сөйләм | 19.04 | | |
| 116 | Сөйләм этикасы | 23.04 | | Сөйләм этикасы белән танышу,план төзү; язма сөйләм нормаларын, язылыш кагыйдәләрен искә төшерү |
| 117. | Сөйләм этикасы | 24.04 | | |
| 118 | Тасвирлау һәм хикәяләү текстлары | 25.04 | | Тасвирлау хезмәтләрне бергәләп бәяләү, хаталарны классификацияләү, автобиография язу үзенчәлеге |
| 119 | Тасвирлау һәм хикәяләү текстлары | 26.04 | | Төрле текстлар төзү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 120 | Тасвирлау һәм хикәяләү текстлары | 30.04 | | Һәр абзацка исем кую, план төзү,эчтәлек сөйләү,орфограммаларны табу,эчтәлеген язу |
| 121 | Тасвирлау һәм хикәяләү текстлары | 1.05 | | |
| 122. | **Контроль изложение “Куян рәхмәте” №2** | 2.05 | | Изложение язу |
| 123. | Хаталар өстендә эш. “Бәйләнешле сөйләм” темасы буенча үткәннәрне ныгыту | 3.05 | | Сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау |
| **Ел буена үткәннәрне кабатлау(13сәг.)** | | | | |
| 124. | “Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе” темасы | 7.05 | | Сүзлекләр белән эшләү |
| 125. | Сүз төзелеше. Сүз ясалышы | 8.05 | | Төзелеше ягыннан сүзләрне тикшерү |
| 126 | Исем Исемнәрнең килеш белән төрләнүе | 9.05 | | Сүз төркемнәрен билгеләү |
| 127. | **Арадаш аттестация№5** | 10.05 | | орфограммаларны кулланып диктант язу; җөмлә кисәкләрен билгеләү |
| 128. | Хаталар өстендә эш. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе | 14.05 | | Сүз төркемнәрен билгеләү |
| 129. | Фигыль | 15.05 | | Җөмлә төзү |
| 130. | Фигыльнең заман белән төрләнеше | 16.05 | | Сүз төркемнәрен билгеләү |
| 131. | Сыйфат | 17.05 | | Сүз төркемнәрен билгеләү |
| 132 | Сочинение “Җәй” | 21.05 | | Җөмлә төзү. Сүзлекләр белән эшләү |
| 133. | Алмашлык | 22.05 | | Алмашлыклар белән җөмлә төзү |
| 134. | Кисәкчәләр. Бәйлекләр | 23.05 | | Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану. |
| 135. | Җөмлә. Сүзтезмә | 24.05 | | Җөмлә төзү |
| 136. | Бәйләнешле сөйләм | 28.05 | | Текст төзү. Сүзлекләр белән эшләү |

**Әдәбият**


1. Татар теле. 1 кисәк, 2 кисәк.- дәреслек  И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова.-Казан,  “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты, 2013 ел
2. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова. Методик кулланма.- Казан,“ Мәгариф- вакыт” нәшрияты, 2013 ел


**Интернет – ресурслар**

татар электрон библиотекасы http://kitap.net.ru/;
татар телендә интернет белем үзәге http://belem.ru//;
балалар өчен сайт http://balarf.ru/.

## Белемнәрне тикшерү өчен материаллар

**Арадаш аттестация эше**

**I өлеш (А)**

А1. Биек сүзенең антонимын тап:
а) зур;  ә) тәбәнәк;  б) кечкенә.
А2. Йөгерә сүзенең синонимын тап:
а) сикерә;  ә) чаба;  б) атлый.
А3. Каенлыкны сүзен төзелеше буенча тикшер:
а) тамыр + сүз ясагыч кушымча;
ә) тамыр + төрләндергеч кушымча;
б) тамыр + сүз ясагыч кушымча + төрләндергеч кушымча;
А4. Бирелгән сүзләр арасыннан бәйлекне тап:
а) гына;  ә) бит;  б) белән.
А5. Дөрес билгеләмәне тап:
а) исем предметның эшен, хәрәкәтен белдерә; ә) исем предметның билгесен белдерә;
б) исем предметны белдерә.
А6. Сәгать сүзендә:
а) 6 хәреф, 6 аваз; ә) 6 хәреф, 5 аваз;  б) 5 хәреф, 6 аваз.
А7. Парлы сүзне тап:
а) савыт – саба;  ә) ап – ак;  б) балачак.
А8. Кушма сүзне тап:
а) бала – чага;  ә) алмагач;  б) карагай.
А9. Табигатне сүзе кайсы килештә?
а) И.к.;  ә) Ю.к.  б) Т.к..
А10. Килгән фигыле кайсы заманда:
а) үткән заман;  ә) хәзерге заман; б) киләчәк заман

**II өлеш (В)**

1) Казансу - Идел елгасының кушылдыгы. 2) Аңа ел саен бик күп күләмдә ташландык сулар агып төшә. 3) Елга буенда ял итүчеләр үзләреннән соң бик күп чуп – чар калдыралар . 4) Аны пычратудан саклау өчен барлык көчебезне куярга кирәк.

В1. Тексттан парлы сүзне күчереп яз.

___________________________________________

В2. Тексттан кушма сүзне табып яз.

___________________________________________

В3. Тексттан аваз һәм хәреф саны туры килмәгән сүзләрне сайлап яз.

___________________________________________

В4. Икенче җөмләнең баш кисәкләрен табып яз.

В5. Беренче җөмләдән нечкә әйтелешле сүзне табып яз.

**Арадаш атестацияләү өчен бәяләү материалы**
**Тестларга куелган таләпләр**
“5” ле - 80-100% үтәлсә;
“4” ле – 60-80 % биремнәргә җавап бирелсә;
“3” ле -40-60 % биремнәр үтәлсә;
“2” ле 40% тан да кимрәк дөрес җавап булса.